**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 28 май № 381

г. Казань

Физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар үткәрү белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (кире кайтаруга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар үткәрү белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (кире кайтаруга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль юнәлештәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы (шул исәптән Татарстан Республикасында яшәүчеләр өчен спорт чараларын һәм бәйрәмнәрен оештыруда һәм үткәрүдә катнашучы) оешмалар чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 6 июль, 553 нче карарын көчен югалаткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\381.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 28 май, 381 нче
карары белән расланган

**Физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар үткәрү белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (кире кайтаруга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар үткәрү белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (кире кайтаруга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба – субсидияләр алучылар).

2. Субсидияләр физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар үткәрү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру белән бәйле килеп чыга торган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (кире кайтару) максатларында бирелә.

Оешмаларның субсидияләр исәбеннән финанслар белән тәэмин ителергә (кире кайтарылырга) тиеш чыгымнары исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү вәкаләтләрен тапшырган орган (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан билгеләнә.

3. Үзләренең оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы юридик затлар субсидияләр алучылар булып тора.

II. Субсидия бирү максатлары, тәртибе һәм шартлары

4. Субсидияләр тиешле финанс елына һәм планлаштырылган чорга Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында күрсәтелгән максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре кысаларында бирелә.

5. Субсидияләр түбәндәге шартларга җавап бирүче юридик затларга бирелә:

юридик зат физик культура һәм спорт өлкәсендә чараларны, яшьләр сәясәте өлкәсендә чараларны, мәдәни-массакүләм чараларны, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чараларны оештыру һәм үткәрү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыра;

юридик затның Россия Федерациясе бюджет системасының бюджетларына мәҗбүри түләүләр буенча кредитор бурычы юк.

6. Субсидия алу өчен юридик затлар вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыра:

вәкаләтле орган раслаган форма буенча исәп-хисаплар һәм чыгымнарны нигезләүләр теркәлгән субсидия бирүгә гариза (алга таба - гариза);

чараны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнар барлыгын раслый торган документлар (күрсәтелгән чыгымнарны каплауга субсидияләр бирелгән очракта);

юридик затның гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга кертелгән барлык үзгәрешләр хакында документлар күчермәләре.

7. Юридик затлар үз теләкләре буенча түбәндәге документларны бирергә хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәве турында таныклау күчермәсе;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

Россия Федерациясе бюджет системасының бюджетларына мәҗбүри түләүләр буенча кредитор бурычы юклыкны раслый торган документ.

8. Юридик зат әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта вәкаләтле орган күрсәтелгән документларны ведомствоара мәгълүмати багланышлар тәртибендә соратып ала.

9. Гариза формасына таләпләр, гаризалар кабул итү башлану һәм тәмамлану вакытлары, шулай ук гаризаларны карап тикшерү графигы вәкаләтле орган җитәкчесе боерыгы белән расланалар. Күрсәтелгән мәгълүмат гаризалар кабул итү башланган көнгә кадәр эш көннәрендә исәпләнүче 10 көн эчендә вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

## III. Гаризаларны кабул итү һәм карап тикшерү

10. Вәкаләтле орган документлар теркәлгән гаризаларны кабул итә һәм кергән көннәреннән соң бер көн эчендә аларны терки.

11. Гаризаны карап тикшерүне вәкаләтле орган аны теркәгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнүче 20 көн эчендә гамәлгә ашыра.

12. Тапшырылган документлар әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәгәндә, вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 11 пунктында билгеләнгән вакыт эчендә тиешле документлар тапшыру кирәклеге турында юридик затка хәбәр итә.

13. Юридик зат белдерү кәгазе алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнүче 3 көн эчендә эшләп бетерелгән яки җитмәгән документларны вәкаләтле органга җибәрә.

14. Юридик зат әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмаганда, вәкаләтле орган белдерү кәгазендә күрсәтелгән вакыт үткән көннән соң бер көн эчендә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

15. Тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе билгеле булганда, вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 11 пунктында билгеләнгән вакыт үткәннән соң эш көннәрендә исәпләнүче бер көн эчендә юридик затка субсидия бирү турында карар кабул итә.

16. Кабул ителгән карар нәтиҗәләре турында белдерү кәгазен вәкаләтле орган тиешле карар кабул ителгән көннән соң бер көн эчендә язмача рәвештә юридик затка җибәрә.

17. Субсидия бирү вәкаләтле орган һәм үзенә карата субсидия бирү турында карар кабул ителгән юридик зат арасында субсидия бирү хакында килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Субсидия бирү хакында килешү билгеләнгән тәртиптә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнүче ике көн эчендә төзелә.

Субсидия бирү хакында килешү формасы вәкаләтле орган тарафыннан раслана.

Субсидия бирү хакында килешүдә субсидиянең зурлыгы, аның максатчан билгеләнеше, физик культура һәм спорт өлкәсендә чараларны, яшьләр сәясәте өлкәсендә чараларны, мәдәни-массакүләм чараларны, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чараларны үткәрү белән бәйле чыгымнар төре, субсидияне күчерү тәртибе, субсидияләрне күчерү вакытлары (шул исәптән агымдагы финанс елында файдаланылмаган субсидия калдыклары финанс ягыннан тәэмин итү чыганаклары булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыруның мөмкинлеге (мөмкин булмавы), субсидияне файдалану турында хисап бирү тәртибе һәм вакыты, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия калдыкларын агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан кире кайтару очраклары (субсидияләрне чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итүгә биргән очракта), вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм аны бирү тәртибен үтәвен тикшерүләр үткәрүгә субсидия алучының ризалыгы, субсидия алучының әлеге Тәртип һәм төзелгән килешү шартларын үтәве турында нигезләмәләр карала.

18. Вәкаләтле орган субсидия бирү хакында килешүләр төзелгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнүче 14 көн эчендә субсидияләрне субсидия алучыларның кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетларына күчерә.

19. Субсидияләр алучылар чараларны оештыру һәм үткәрү буенча чыгымнарның аерым хисап исәбен алып баралар.

20. Бирелгән субсидияләр субсидияләрне бирүнең әлеге Тәртип белән билгеләнгән максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан билгеләнешендә файдаланмау һәм (яки) субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыру фактлары билгеле булып, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының тиешле таләбен алганнан соң 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты табышына кире кайтарылырга тиеш.

21. Чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итүгә субсидияләр бирү турында килешүләрдә каралган очракларда хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия

калдыклары хисап елыннан соң елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты табышына субсидия алучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

22. Әлеге Тәртипнең 20 һәм 21 нче пунктларында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты табышына ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, алар законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә алынырга тиеш.

23. Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен субсидия алучылар тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыралар.

24. Бюджет чараларын максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны вәкаләтле орган гамәлгә ашыра.

F:\KARAR\2015\381-1.docx